СОВЕТ ЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д.9, с. Нижние Яки
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422157

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яңа ур., 9 нче йорт, Түбән Яке авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422157

тел.(факс): (85563) 2-94-38; e-mail: Yak.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

«05 »июнь 2018 ел № 3-34

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыЯке авыл җирлеге Советының2016 елның 29 июлендәге 1-11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыЯке авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы нигезләмәгәүзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советының 2016 елның 29 июлендәге 1-11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 3.2 пунктчасының 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне, әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру»;

1.2. 4 пунктның 4.6 пунктчасының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«-җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыра.

Җирлек территориясен төзекләндерүне тормышка ашыру үз эченә ала:

1) гомуми файдаланудагы территорияләрне карап тоту һәм мондый территорияләрдән файдалану тәртибе;

2) биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның фасад һәм киртәләү конструкцияләренең тышкы төре;

3) төзекләндерү элементларын проектлау, урнаштыру, карап тоту һәм торгызу, шул исәптән җир эшләрен башкарганнан соң да;

4) җирлек территориясен, шул исәптән биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны архитектур яктыртуны да кертеп, яктыртуны оештыру.;
5) җирлек территориясен яшелләндерүне оештыру, шул исәптән торак пунктлар чикләрендә урнашкан газоннарны, чәчәк түтәлләрен һәм үлән үсемлекләре белән башка территорияләрне булдыру, карап тоту, торгызу һәм саклау тәртибен дә кертеп;
6) авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат урнаштыру, шул исәптән урам исемнәре һәм йорт номерлары, элмә такталары куелган күрсәткечләр урнаштыру.;
7) балалар һәм спорт мәйданчыкларын, хайваннарны урамда йөртү өчен мәйданчыкларны, парковкаларны (парковка урыннарын), кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту;;
8)җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән тротуарларны, аллеяларны, юлларны, сукмакларны оештыру.;
9) күрсәтелгән территория буенча инвалидларның һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итү максатларында җирлек территориясен төзекләндерү;;
10) җирлек территориясен җыештыру, шул исәптән кышкы чорда;
11) яңгыр суларын агызуны оештыру;
12) җир эшләрен үткәрү тәртибе;
13) тирә-юнь территорияләрен карап тотуда, шул исәптән, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның, җир кишәрлекләренең финанс, милекчеләрнең һәм (яки) башка законлы хуҗаларының (күпфатирлы йортлардагы биналарның милекчеләреннән һәм (яки) башка законлы хуҗаларыннан тыш), катнашуы; (2018 елның 28 июненнән үз көченә керә)
14) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә тирә-юнь территорияләре чикләрен билгеләү; (2018 елның 28 июненнән үз көченә керә)
15) җирлек территориясен бәйрәмчә бизәү;
16) җирлек территориясен төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыруда гражданнар һәм оешмаларның катнашу тәртибе;
17) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне тикшереп тору.»; 1.3. 4.11 пунктының 12 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) юлы белән бастырып чыгарырга(халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Яке авыл җирлеге башлыгы Р.К.Низаметдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Яке авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе /Р.К.Низаметдинов/